СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**29 ноябрь 2019 ел** **№ 5**

**Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 37 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм уткәрү турында Нигезләмә нигезендә, Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылы, Урта урам, 25 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2019 елның 11 декабернә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылы, Урта урам, 25 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2019 елның 12 декаберенә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Урта урамда яшәүчеләр

2нче этап: Г.Гафиятуллин, Югары, Түбән урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез

- 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

юл-урам челтәре нигезен вак таштан каплау, Каенсар авылы, төп юлдан Урта урамның 31 нче йортка кадәр.

- 2019 елның 13 ноябрендәге 1 номерлы "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылында халык җыены нәтиҗәләре турында» карарны юкка чыгарырга

ризамы»?

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Каенсар авылы, Урта урам, 25 йорт; ТР, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы А.И. Сафин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯНГА-САЛСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * ИНН 1609003024
СОВЕТ ЯНГА-САЛСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ